Алга, белем иленә!

# Мәктәбем минем

Казан шәһәре Идел буе районының 78 нче урта гомуми
белем мәктәбе укучыларының нәфис басмасы

21 декабрь, 2013 ел
№2



## Әлеге санда:




Тарих сәхифәләре (2 нче бит )



Сәламәт тәндә—сәламәт акыл! (3 нче бит)



Илһам канатында (4 нче бит )



Мәктәп дәрьясында…

(6 нчы бит)

**Хуш киләсең, Яңа ел!**

**Ак чәчәк кебек кар ява**
**Урманнарга, кырларга.**
**Тынычлык алып Яңа ел**
**Килсен бөтен дөньяга!**
**Кыш бабай, Кыш бабай**
**Безне бик ярата.**
**Ул безгә Яңа ел**
**Бүләге тарата!**





### Мәктәп кунаклар кабул итә!

Федераль дәүләт стандартлары мәктәбебезнең һәр дәресенә, сыйныфтан тыш чараларына көчле агым булып үтеп керде. Икенче чиректә генә дә берничә тапкыр республикабыз төбәкләреннән Казанга белемнәрен камильләштерү өчен килгән мәктәп директорлары, аларның урынбасарлары, укытучылары безгә тәҗрибә уртаклашырга җыелды. Үткәрелгән ачык дәресләр һәм дуслык бәйрәме оешкан төстә, күңелле һәм файдалы үтте, кунакларның югары бәясен алды.

**Мөхәррирләр**

## Мәктәп хәбәрләре:

1. Икенче чиректә мәктәп республика төбәкләреннән күп кунаклар кабул итүе белән истә калыр.

2. «Сабантуй» газетасының беренче битендә безнең мәктәп турында зур мәкалә 1әм фотосурәтләр басылып чыкты.

3. Коррупциягә каршы язылган иншалар конкурсында Ногаев Илнур (8 М сыйныфы) 3 нче урын яулады. ( Җитәкчесе: М.Т. Инсафутдинова).

4. 23 нче декабрьдә өлкән сыйныф укучылары өчен дискотека булачак, ә 24 нче декабрь нәниләрне чыршы бәйрәмнәре белән сөендерәчәк.

5. 25 –31 нче декабрь көннәрендә кышкы лагерь укучыларны үзенә көтеп кала.

6. Сөенче! 31 нче декабрьдә Олимпия утын каршылаячакбыз!

## Күренекле татар әдибе Шәүкәт Галиевка 85 яшь

.

Шәүкәт Галиев (Шәүкәт Галиулла улы Һидиятуллин) 1928 елның 20 ноябрендә Татарстан АССРның Апас районы Олы Бакырчы авылында крестьян гаиләсендә туа. 1943 елда җидееллык мәктәпне тәмамлый һәм туган колхозында эшли башлый. 1945—1953 елларда ул хисап эшләрендә, район газетасында эшли, 1950 елда КПСС сафларына керә. 1953 елдан алып ул «Чаян» журналы редакциясендә эшли. 1956 елда эшче яшьләр кичке урта мәктәбен тәмамлый. 1959—1961 елларда Мәскәүдә СССР Язучылар союзы каршындагы Югары әдәби курсларда укый. Әдип 1958 елда СССР Язучылар союзына кабул ителә. 1961 — 1971 елларда ул — профессиональ язучы, ә 1984 елга кадәр — Татарстан китап нәшриятында матур әдәбият редакциясе мөдире.

Ш. Галиевның беренче шигырьләре 1948 елда басылып чыга. Шуннан соң шагыйрь үзенең әдәби иҗат эшен киң җәелдереп җибәрә. Ш. Галиев танылган балалар шагыйре. 1972 елда бу өлкәдәге әсәрләре өчен ул Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды. 1980 елда аның балалар өчен язылган шигырьләре «Заяц на зарядке» исеме астында рус теленә тәрҗемә итеп басылды. 1982 елда шагыйрь бу китабы өчен Халыкара бүләккә— Г.Х.



Дипломга лаек булды һәм Халык шагыйре дигән олы исемгә лаек булды.

Ш. Галиев шулай ук олылар өчен язылган лирик шигырьләре, җырлары, бигрәк тә сатира-юмор әсәрләре белән дә әдәбият сөючеләрнең игътибарын җәлеп итте.

Шәүкәт Галиев — балалар әдәбиятында шаян шигырләре белән мәгълүм шагыйр. Ул тормышның кызыклы якларын табып балалар белән бүлешә, аларны рәхәтләнеп көлдерә, яхшыны начардан, затлыны зат-сыздан аерып күрсәтә. Шуңа да шагыйр сурәтләгән хәлләр үтемле булып йөрәккә керә, онытылмый, гел укучыны үзенә тарта.


**Материалны Ильвина Садреева һәм Рамил Хасаншин әзерләделәр**


### Сабантуйда җиңелгән малай

Җилкенеп чыкты уртага,
Үзе дә белми нидән —
Ахры мәйданга ашкыну
Җитмеш бабадан калган.
Карыйлар җиде яшлеккә
Көрәшче итеп зурлап,
Алды ул иплэп сөлгене,
Бик оста гына урап.
Уйламый кем алдында да



Һич артка чигәрмен дип,
Ышанып, көч тоеп чыккан
Әлбәттә җиңәрмен дип.
Аңа каршы баскан малай
Озынрак шул бер башка,
Үзең ега алмасаң да,
Тырыш син егылмаска.









## Сочи Олимпиадасы—2014

1) **2014 елның 7-23 февралендә 16 көн дәвамында XXII Олимпия уеннары узачак;**

2) **2014 елның 7-16 мартында 9 көн XI Паралимпия уеннары булачак;**

3) **98 комплект медальләрне 7 төрле олимпия уеннарында уйнатачаклар;**

4) **64 комплект медальләрне 5 төрле паралимпия уеннарында уйнатачаклар ;**

5) **25 мең волонтер Сочи Олимпиадасы уеннарында эшләп йөриячәк;**

6) **Сочи Олимпиадасында 80 ил катнашачак ;**

7) **12 меңгә якын фотографлар һәм журналистлар аккредитация үтәчәк.**



## Казанга Яңа ел алдыннан

Олимпия уеннарының төп символларыннан берсе булган утны дүрт ай дәвамында илнең барлык төбәкләрендә дә күрәчәкләр. Гомумән алганда, Россиядәге этап Олимпия уты тарихында иң зурысы булачак. 123 көн эчендә ут 63 мең чакрым ара узар дип көтелә. Утны Байкал күле төбенә дә алып төшәчәкләр, Эльбрус түбәсенә дә алып менәчәкләр, Төньяк котыпка да алып барачаклар, хәтта галәмгә дә очыртырга җыеналар.

Россия Президенты Владимир Путин катнашында узган каршы алу тантанасыннан соң Мәскәүдән утны Санкт-Петербургка алып китәләр. 23 көн эчендә ул Үзәк һәм Төньяк Көнбатыш федераль округ шәһәрләре буенча сәяхәт итәчәк. Аннары ул бер ай дәвамында Төньяк һәм Ерак Көнчыгышта булачак. Эстафетаның киләсе этабында аны илнең 58 шәһәрендә күрсәтмәкче булалар. Сочига утны 7 февральдә алып киләчәкләр.

Олимпия уты, алдан хәбәр ителгәнчә, Казанга 30-31 декабрь көннәрендә килеп җитәр дип көтелә. Бездән ул Ижауга китәчәк, диләр. Әлегә Татарстан этабында эстафетада кемнәр катнашасы төгәл аталмаса да, үзәк матбугатлар утны йөртүчеләр арасында Татарстанның элеккеге спорт министры, Россия Олимпия комитетының генераль секретаре Марат Бариев булыр дигән хәбәрләр бар.




# Илһам канатында

## Тиздән Яңа ел

Агачлар әллә кайчан инде алтын яфракларын койдылар, көннәр дә салкынайтты. Әле кичә генә кечкенә Куянкай Аю янына килеп: "Кара нинди матур яфраклар", дип килгән иде, ә хәзер инде бөтен җирдә ап-ак кар ята. Куянкай Яңа Ел бәйрәменә әзерләнергә кирәк дигәч, аю көлеп куйды да, кәкре аяклары белән, дәшми, китеп тә барды.

Куян да үзенең өенә кайтып китте, ул Яңа елга бүләкләр әзерли башлады! Шулай әле котлау язып, әле төсле кәгазьдән уенчыклар ясап, куян йокыга киткәнен сизми дә калды. Бер-ике сәгать үткәч, Куянкай күзен ачып җибәрсә, аның янында Кар кызы утыра икән! Куянкай куркып, өеннән чыгып чапты. Иң якын дусты - Аю янына йөгереп килде. Ишеге ябык икән Аюның. Куянкай күпме шакыса да, ишекне ачмый ул. Аю дус, димәк, күптән йокыга киткән, аның белән хәзер бары тик, яз көне генә сөйләшеп булачак. Эх, Аю- Аю, дип әйтә Куянкай, шулай йоклап, бернәрсә дә күрмичә кала ич бу! Куянның инде башы катып, Бурсык янына китә. Бурсык та өендә үз эшләре белән мавыккан, Куянкайны өенә кертеп тә тормаган.

Урманда салкын. Куянкай әкрен генә кар өстенә басып, уйлана -уйлана, өенә дә кайтып җиткән. Өенә кергәч Кар кызы: "Куянкай ник куркасың син миннән, мин бит сиңа кунакка гына килдем", дип әйтә икән.



Куянкайның аягы калтырана, ул куркып әйтә: "Мин синнән курыктым, син мине ашарсың дип белдем",- ди. Аннары алар сөйләшеп киткәч, дуслашканнар. Яңа елны бергә каршы алганнар. Куянкай аны сыйлаган, чәйләр эчерткән. Хәзер Куянкай һәр елны Кар кызын көтеп ала икән, алар бергәләп Яңа елны каршылый торган булганнар. Куянкай өчен кышның килүе дә бәйрәм, чөнки ул кыш көне матурлана, йоннары кабарып, ап-ак өскә керә бит!

**Алсу Әхмәдуллина,
6 нчы Г сыйныфы
укучысы**



## Бик зур мәче

Зоопаркта Наилә –
Шаккатты!
Юлбарысны күреп, телен
Шартлатты:
- Күргәнем юк иде монда
Килгәнче,
Ой! Бигрәк зур икән ич бу
Мәче!
Тотар өчен моңа тычкан
Сирәктер?
Аңа, бәлки, бик зур тычкан –
Кирәктер?
Абыйсына борылып:
- Абый, - ди, -
Гулливерлар асрыймы соң
Аны, - ди!

**Динә Дәминова,
3 нче сыйныф укучысы**

## Әнием

Әнием! Әнием!
Беренче сүзем син,
Мәңгегә йөрәктә,
Уелган җырым син!

Гомерем буена
Яшәргә көч бирдең.
- Тормышың юлыңда
Изгелек кыл, - дидең.

Карашың, киңәшең
Һавадай кирәктер.
Мең яшә әнием,
Син безгә терәктер!

**Алсу Әхмәдуллина,
6 нчы Г сыйныфы
укучысы**

# Редакциягә килгән хатлар



**Яңа ел алдыннан балалар безнең редакция аша Кыш Бабайга бик күп хатлар яздылар. Менә килгән хатларның берничәсен бастырырга булдык:**

Исәнме, Кыш Бабай! Сиңа Якубов Илгиз хат яза. Мин Казанның 78 нче мәктәбенең 6 нчы Г сыйныфында укыйм. Безнең сыйныфта 32 укучы. Көзгә багышланган кул эшләре конкурсында без алдынгы урынны яуладык. Беренче чирекне мин «4»ле һәм «5» ле билгеләренә генә тәмамлаган идем. Икенче чирек тә тәмамланып килә, аны да яхшы билгеләргә генә бетерергә җыенам.

Кыш Бабай, син салкын якларда ничек яшәп ятасың? Сәламәтлегең ничек? Барлык балаларга да бүләк өләшергә каян көч һәм вакыт табасың?

Минем дә сиңа зур бер үтенечем бар иде. Миңа Яңа елга телефон бүләк ит әле?!

**Илгиз Якубов,**
**6 нчы Г сыйныфы укучысы**

Кадерле Кыш Бабай! Мин ел буе яхшы булдым. Мин Яңа елга песи баласын бүләккә бирүеңне телим. Кар кызына миннән күп итеп сәламнәр әйт. Бәхет телим сиңа!

Сау бул!

**Диана Новосельцева,**
**6 нчы М сыйныфы укучысы**




Исәнмесез, Кыш Бабай! Минем исемем Настя. Миңа унөч яшь. Яңа елда минем әти-әнием, дусларым исән-сау булсыннар, авырмасыннар.

Киләсе ел күңелле, әйбәт, матур үтсен!

**Настя Хомкова,**
**6 нчы Г сыйныфы укучысы**

Исәнме, Кыш Бабай! 2014 нче ел белән сине! Зинһар өчен, миңа фотоаппарат алып бир әле. Әти-әнием сәламәт булсыннар. Менә дөньяда инвалид балалар бик күп. Әлеге балалар да иртә белән күзләрен ачуга терелсеннәр иде. Ярар, Кыш Бабай, рәхмәт, сау бул!

**Ильвина Садреева,**
**6 нчы Г сыйныфы укучысы**



Исәнме, Кыш Бабай! Сиңа Глеб хат яза. Мин 6 нчы сыйныфта укыйм. Бу елны мин үземне тәртипле генә тоттым. Әниләремә дә гел булышам: өйне җыештырам, энемне дә карыйм. Яхшы гына укыйм. Кыш Бабай, табигатебез һәрвакыт матур, ямьле булсын иде. Кыш икән, аның бураннары уйнасын; җәй икән, яңгырлары да вакытында явып торсын иде. Кыш Бабай, минем теләгемне онытма инде! Әлегә сау булып тор!

**Глеб Купцов,**
**6 нчы М сыйныфы укучысы**

Кадерле Кыш Бабай! Киләсе 2014 ел белән сине котлыйм! Минем Яңа елга синнән күп нәрсә сорыйсым килә: минем әтием, әнием, абыем исән-сау булсыннар. Дустым Ильвинага туфли алып бирсәң иде. Үскәч, мин үзем эшләп, машина аласым килә.

Кыш Бабай, син дә беркайчан да авырма. Тагын бер кат бәйрәм белән!

**Алсу Әхмәдуллина,**
**6 нчы Г сыйныфы укучысы**

# Мәктәп хәбәрләре

## «Сабантуй» бездә кунакта



28 нче ноябрьдә ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре, баш мөхәррир урынбасары Рәзинә Әхтәм кызы Исмәгыйлова белән очрашу үткәрелде. Ул “Сабантуй” газетасының үткәне, бүгенгесе белән таныштырды, 2014нче елда аның журнал булып, айга ике мәртәбә чыгачагын җиткерде.

“Сабантуй” газетасында минем шигырьләрем, әкиятем басылып чыкты. Үскәч, минем дә журналист буласым килә. Ләкин журналист һөнәрен үзләштерү өчен зур тырышлык һәм күп укырга кирәк. Җәмгыятьтә булган һәр яңалыкны көне-сәгате белән укучыларга җиткерү журналисттан зур осталык һәм намус таләп итә. Әгәр яңалыкларны җиткереп торучы газета-журналлар, радио-телевидение, интернет булмаса, без күп нәрсәдән мәхрүм булыр идек.

Мондый кызыклы очрашулар безнең мәктәптә ешрак булсын иде.

**Алсу Әхмәдуллина,**
**6 нчы Г сыйныфы укучысы**



## Артистлар белән очрашу

Безнең мәктәп күп еллар Кәрим Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры белән хезмәттәшлек итә. 18нче декабрьдә театрның талантлы яшь артистлары: Татарстанның атказанган артисты Ренат Шәмсетдинов, Гөлчәчәк Хафизова һәм Алмаз Фәтхуллин белән очрашу үтте. Кичәбез сөекле шагыйребез Г.Тукайның “Театр” шигыре белән башланып китте һәм җылы, дустанә мөнәсәбәттә дәвам итте.

Артистлар “Али баба һәм өч карак” исемле әкияттән өзек куйдылар. Барлык балалар да әлеге өзекне бик кызыксынып карап утырдылар. Төсле, матур, борынгы киемнәрен киенгән артистларыбыз сәхнәдә искиткеч оста уйнаулары, тапкыр һәм кызыклы җаваплары, гадилекләре белән таң калдырдылар.

Очрашу кичәсе бик күңелле, файдалы узды. Һәр кешенең йөзендә елмаю балкый иде. Барлык укучыларга да әлеге очрашу бик ошады.

**Гөлмирә Батталова,**
**6 нчы Г сыйныфы укучысы**

### Кадет анты бирү көне

10 нчы декабрь көнне безнең мәктәптә кадетларның ант бирү көне, ягъни кадетка кабул итү көне булып узды. Барлык балалар да әлеге көнгә ныклы әзерлек белән килделәр. Аеруча былтыр кадетларга кабул ителгән сыйныфлар, ягъни 6 нчы К һәм 7 нче К сыйныфлары үзләрен үрнәк яктан күрсәттеләр. Алар барабаннар, агач кашыклар белән уйнаулары белән дә сокландырдылар.

**Айсылу Фаезова,**
**8 нче М сыйныфы укучысы**





### Өлкән сыйныф укучылары советына вәкилләр сайлау

29 нчы ноябрь көнне мәктәптә өлкән сыйныф укучылары советына вәкилләр сайлау көне булды. Әлеге көнне этажларда сайлау бюллетень тартмалары куелган иде. Сайлауларда 8-10 нчы сыйныф укучылары, укытучылар да актив катнаштылар.

**Илгиз Якубов,**
**6 нчы Г сыйныфы укучысы**



### Дуслык белән көчле без «В слове мы сто тысяч я» концерты

11 нче декабрь көнне «Без дигән сүздә йөз мең мин» дигән концерт булып узды. Әлеге концерт халыклар дуслыгына багышланган иде.

Татарстаным − дуслык иле!

Халыклар дуслыгы – Татарстанның байлыгы. Татарстанда бүген 120 дән артык милләт вәкиле һәм этник төркемнәр яши. Республикабыз халыклары, үзара бәйләнешләр нәтиҗәсендә өлкәләрдә бер-берсенә йогынты ясап, дус һәм тату тормыш итәләр. Ә җөмһүриятебезнең беренче президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиев: “Кем ул иң бәхетле кеше? Кемнең татар, рус, чуваш, удмурт һ.б. милләт кешеләре арасында дуслары күп, шул бәхетле”, – дигән. Татарстан халыклары үзара бәйләнешләр нәтиҗәсендә, тел, мәдәният һәм башка өлкәләрдә бер-берсенә йогынты ясап, күркәм тормыш итәләр.

Аларның киләчәккә омтылышлары, уйхыяллары бер-берсенә охшаган кебек. Татар шагыйре Һади Такташ үзенең шигырендә:

«... нинди охшаганбыз,
Ничек охшаганбыз,
Бертуганнар дисәң,
Мин – Тамбовтан, ә син –
Казан артыннан;
Мин бер мишәр улы, кыргый үскән,
Ә син
Күрше чуваш халкыннан...», – дип дөрес язган.

**Ильвина Садреева,**
**6 нчы Г сыйныфы укучысы**

# Эш беткәч, уйнарга ярый



## Ат елы нindirәк булыр икән?

Яңа елның уңышлы, имин һәм мул буласына өметләр зурдан. Татар халкы өчен ат – хөрлек, ирек символы. Атка атланып, тезгенне нык тотып, бабаларыбыз дөньяны тетрәткән. Вакыт-вакыт, үзебез дә сизмәстән, шул чорларны күңелдән кичерәбез, үткәнебез, бүгенгебез белән горурланабыз. 2014 елның символы гадәти генә ат түгел. Көнчыгыш ышануларына караганда, ул – зәңгәр төстәге агач ат. Андый ат үзенә игътибарны җәлеп итми. Ул уйланырга ярата. Әңгәмәдәшен тыңлый, аңлый белә һәм кирәк булса, аны үз урынына утырта ала. Агач атның бер уңай сыйфаты – активлык. Өстәвенә ул тырыш та. Югарыдагы сыйфатларга ия булучылар өчен киләсе елда бәхет елмаячак.



Яңа ат елында ат кебек тырышып эшләп, аек фикер йөртеп, куелган максатларыбызны тормышка ашырып яшәргә язсын, дуслар!

**Айгөл Мәрдәнова,**
**7 нче Г сыйныфы укучысы**

# Котлыйбыз!

**78 нче мәктәп укытучылары һәм укучылары тылсымлы, буранлы кыш көннәренә туры килгән туган көннәрен билгеләп үтүче укытучыларны котлый:**

**Инсафетдинова Миләүшә Тәлгатовна**
**Хорина Нина Федоровна**
**Кофтункина Елена Валентиновна**
**Опарина Лилия Фәридовна**
**Габдулина Альмира Фердинантовна**
**Приходько Надежда Анатольевна**
**Роганова Татьяна Николаевна**
**Исмаилова Люция Исраиловна**
**Яковлева Евгения Николаевна**
**Ильина Валентина Ивановна**

**Гомерегез хәзинәсенә**
**Өстәлде тагын бер ел.**
**Моңаймагыз еллар үтә дип,**
**Алда көтә зур, бәхетле юл!**
**Котлы булсын бәйрәмнәрегез,**
**Тыныч булсын күңелләрегез,**
**Шатлык-сөенечләр белән**
**Тулы булсын гомерләрегез!**
**Гамьле еллар, ямьле көннәр**
**Телибез чын йөрәктән!**
**Һич кичекми чынга ашсын**
**Безнең күркәм теләкләр!**



**Мөхәррирләр:** С.Сөләйманов, Ф. Ай-сылу, Я. Гадел, Г.Батталова, М. Айгөл, Р. Идрисов, Я. Илгиз, А.Әхмәдуллина, Д.Мостафаева, С. Ильвина, Х. Рамил, М.Ләйлә
**Консультант:** Л. И. Исмаилова




Безнең адресыбыз: Казан шәһәре Идел буе районы 78 нче урта белем бирү мәктәбе (Ю. Фучик урамы, 40 нчы йорт), 420139
тел./ факс 268-58-61
E-mail: school_7878@mail.ru S78kzn@edu.tatar.ru
Газетабызны түбәндәге сайттан күрергә мөмкин:
https://edu.tatar.ru/priv/school78.htm/page813169.htm
Хатларыгызны түбәндәге адреска юллагыз:
lyutsiya_906@mail.ru